РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

МЕШИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422062, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.Лесхоз, ул. Кукморская, 2а
тел. (84363) 44-2-19

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422062, Татарстан Республикасы,
Лесхоз бистэсе, Кукмара урамы, 2а йорт

e-mail: Mesh.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

29.07.2024 — №29

Саба муниципаль районы Мишә авыл
Башкарма комитетының 16.03.2016 елда 8 номерлы
карары белән расланган Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Мишә авыл
Башкарма комитетының гражданнар мөрәҗәгатьләрен
карау һәм вазыйфаи затларның шәхси кабул итү
тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 09.12.2023 елгы №124-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына таянып Саба районы Мишә авыл башкарма комитеты карар итә:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл башкарма комитетының 16.03.2016 №8 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл башкарма комитетының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм вазыйфаи затларның шәхси кабул итү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл башкарма комитетының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.1. 7 пунктның 7.2 пунктчасында «электрон адрес» сүзләрен«федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланганда электрон почта адресы йә шәхси кабинет адресы (уникаль идентификаторы) «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең)Бердәм порталы,» дигән сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 7 пунктның 7.3 пунктчасында «электрон почта адресы» сүзләрен «электрон почта адресы йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы,» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 14 пунктның 14.9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм мондый балаларны озата баручы затлар ия.

Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар.»

1.4. 18 пунктның 5 пунктчасын «күрсәтелгән электрон почта адресы буенча» сүзләрен «электрон почта адресы буенча яисә шәхси кабинет адресы буенча күрсәтелгән Бердәм порталда» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru Саба муниципаль районының Мишә авыл җирлегенең рәсми сайтында https://pravo.tatarstan.ru/npa_msu/saby/meshin.htm адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы А.Х.Гатиятуллин